КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 сентябрь г.Казань № 768

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

IV бүлектә:

1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 82 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыя тауга менү | 2,2 | 3,3 | 6,3 | 8,3 | 8,3 | 14,3 | 16,7 | 20,0 | 33,3 | 51,9 | 88,9»; |

2 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 82 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыя тауга менү | 4 | 6 | 9 | 12 | 12 | 18 | 18 | 18 | 24 | 28 | 32»; |

3 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 82 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «82. | Кыя тауга менү | 10 | 10 | 8 | 8 | 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 2»; |

VIII бүлекнең 9 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Спорт резервын әзерләү оешмасын гамәлгә куючы тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен әлеге оешма җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләргә мөмкин.

Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләргә мөмкин.

Чираттагы финанс елына тренер-укытучыларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы һөнәри белем бирү оешмасы һәм спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{VKS_{ruk_i}} = \frac{\sum V_{VKS_{ruk_{svod}}}}{\sum V_{VKS_{tren\text{-}pred_{svod}}}} \times \sum V_{VKS_{tren\text{-}pred_i}},$$

монда:

$V_{VKS_{ruk_i}}$– чираттагы финанс елына тренер-укытучыларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы i-һөнәри белем бирү оешмасы һәм спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме;

$V_{VKS_{ruk_{svod}}}$– агымдагы финанс елына кадәрге елга тренер-укытучыларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы һөнәри белем бирү оешмасы һәм спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына

стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнарның гомуми күләме;

$V_{VKS_{tren\text{-}pred_{svod}}}$ – агымдагы финанс елына кадәрге елга югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы һөнәри белем бирү оешмасы һәм спорт резервын әзерләү оешмалары тренер-укытучыларына айлык бүләкләүләрне түләү чыгымнарының гомуми күләме;

$V_{VKS_{tren\text{-}pred_{i}}}$– агымдагы финанс елына кадәрге елга югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы i-һөнәри белем бирү оешмасы һәм спорт резервын әзерләү оешмалары тренер-укытучыларына айлык бүләкләүләрне түләү чыгымнары күләме.

Тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен i-спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы акча оешма җитәкчесен кызыксындыруга 50 процент күләмендә һәм оешма җитәкчесе урынбасарларын, баш бухгалтерын кызыксындыруга 50 процент күләмендә бүленә.

Тренерларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин